МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Кремлевская, д.9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

Кремль ур., 9 нчы йорт, Казан шәһәре, 420111

Тел.: (843) 294-95-90, факс: (843) 292-93-51, e-mail: Minobr.Priemnaya@tatar.ru, сайт: mon.tatarstan.ru

____________________№________________

На №________________от________________

**Татарстан Республикасы
муниципаль районнары
башкарма комитетларының
мәгариф идарәләре
(бүлекләре) җитәкчеләренә**

"Белем җәүһәрләре - 2016"
VII Бөтендөнья интернет-проектлар
бәйгесе турында

**Хөрмәтле коллегалар!**

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын тормышка ашыру, туган телгә һәм гореф-гадәтләргә мәхәббәт тәрбияләү, интернет-технологияләр ярдәмендә татар телен һәм мәдәниятен саклау һәм үстерү, прогрессив белемле укытучылар, укучылар һәм гаиләләрне барлау максатында "Белем җәүһәрләре" дип исемләнгән VII Бөтендөнья интернет-проектлар бәйгесен үткәрә (алга таба – Бәйге).

Гаризалар электрон рәвештә 2016 елның 15 нче сентябренә кадәр Бәйгенең рәсми сайтында (http://konkurs.belem.ru) кабул ителә.

Белешмәләр өчен телефон: +7(960)045-63-53 (Гатауллин Раил Мәүлет улы, оештыру комитеты рәисе), электрон адрес: xat@belem.ru.

Кушымта: нигезләмә 4 биттә 1 нөсхәдә.

**Министр урынбасары** **И.Р. Мөхәммәтов**

Р.Т. Кәримов,
(843)2949510


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

**«Белем җәүһәрләре – 2016»**
**VII Бөтендөнья интернет-проектлар бәйгесе нигезләмәсе**

## I. Гомуми нигезләмә

1.1. «Белем җәүһәрләре - 2016» VII Бөтендөнья интернет-проектлар бәйгесенең (алга таба - бәйге) максатларын, бурычларын, катнашу кагыйдәләрен, оештыручыларның һәм катнашучыларның хокукларын, үткәрү һәм җиңүчеләрне бүләкләү тәртибен билгели.

1.2. Бәйгенең төп оештыручылары:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы.

## II. Бәйгенең максатлары һәм бурычлары

2.1. Бәйге уздыруның төп максаты һәм бурычлары:

фән, мәгариф һәм мәдәният өлкәсендәге татарча интернет-ресурсларны эзләп табу һәм аларны популярлаштыру;

Татарстан Республикасында һәм аннан читтә яшәүче татарларга куллану өчен файдалы интернет-ресурсларны бер урынга туплау;

фән, мәгариф һәм мәдәният өлкәсендәге татарча интернет-ресурсларның сыйфатын яхшыртуда консультацион ярдәм күрсәтү;

интернет челтәрендә фән, мәгариф һәм мәдәният өлкәсендәге интернет-ресурсларны булдыру өстендә эшләүче белгечләргә ярдәм күрсәтү, таныту, аларның бергәлеген булдыру.

## III. Бәйгене оештыру комитеты

3.1. Бәйгене оештыру буенча мәсьәләләрне хәл итү өчен бәйгенең Оештыру комитеты төзелә.

3.2. Оештыру комитетына йөкләнгән бурычлар:

бәйгенең нигезләмәсен булдыра, аны камилләштерә һәм аның үтәлүен тәэмин итү өстендә эшли;

бәйгене үткәрү шартларын (үткәрү кагыйдәләрен, вакытын, бәяләү критерийларын, этапларын һ.б.) билгели;

жюри составы турында карар кабул итә;

бәйгедә катнашырга теләк белдергән кулланучылардан гаризалар җыя, гаризаларның төгәл бирелүен, язылышын, нигезләмә таләпләренә туры килүен тикшерә;

бәйге барышында жюри һәм экспертлар эшен координацияли;

номинантлар арасында халык тавышын белү системасын оештыра, гаделлеге өчен җавап бирә;

бәйгедә җиңүчеләрне бүләкләү тантанасын оештыра;

бәйгенең рәсми сайтында мәгълүмат базасын һәм архивын булдыра һәм аның иминлеген тәэмин итә, бәйге яңалыкларын урнаштырып бара;

башка төр оештыру сорауларын хәл итү максатыннан тиешле карарлар кабул итә.

3.3. Оештыру комитеты:

әлеге нигезләмәнең 8.3. пунктында күрсәтелгән критерийлар буенча Бәйгегә килгән гаризаны кире кагарга;

нигезләмә тарафыннан урнаштырылган кагыйдәләрне бозу, Бәйгене үткәрү таләпләренә һәм шартларына туры килмәү очракларында Бәйгедә катнашучыны Бәйгедә катнашу мөмкинлегеннән мәхрүм итәргә хокуклы.

3.4. Оештыру комитеты әгъзалары Бәйгедә үзләренең шәхси интернет-проектлары белән катнаша алмыйлар.

## IV. Экспертлар берләшмәсе

4.1. Экспертлар берләшмәсе, әлеге нигезләмәнең 7.1 пунктында расланган бәйге критерийларына таянып, бәйгегә тәкъдим ителгән эшләр арасыннан жюри әгъзаларына номинантларны һәм җиңүчеләрне тәкъдим итәргә хокуклы.

4.2. Бәйгедә катнашкан сайт авторлары эксперт була алмый.

## V. Жюри

5.1. Жюри составына татар телен, мәгълүмати технологияләрне яхшы белгән, мәгариф һәм мәдәният өлкәсе белән якыннан таныш компетентлы белгечләр кертелә.

5.2. Жюри әгъзасы булырга теләк белдергән физик зат бәйгенең рәсми сайты (жюри битендә) аша үзенең гаризасын калдыра ала.

5.3. Жюри әгъзасының хокуклары:

һәр ел саен номинацияләр санын һәм номинацияләү принципларын билгеләүдә катнаша;

нигезләмәдә расланган бәйге критерийлары буенча бәйгедә катнашучылар арасыннан номинантларны билгели;

экспертлар һәм бәйгенең сайтындагы халык фикерен исәпкә алып, җиңүчеләрне билгели.

## VI. Бәйгедә катнашучыларның хокуклары

6.1. Бәйгедә катнашу өчен татарча интернет-проектлар тәкъдим ителә. Бәйгедә катнашырга теләк белдергән интернет-проект интернет челтәрендә ким дигәндә 1 айдан артык эшләп килергә, эзләү системаларында табылырга тиеш.

6.2. Бәйгедә катнашу өчен гаризаны интернет-проектны ясаган web-осталар яисә интернет-проект хуҗалары гына бирә ала. Гариза бирүче бәйгедә берничә интернет-проект белән катнаша алырга хокуклы.

6.3. Интернет-проект катнашачак номинацияне гариза тапшыручы үзе билгели.

## VII. Бәйгедә катнашучы Интернет-проектларны бәяләү

7.1. Интернет-проектлар түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә:

«Функциональлек һәм технология ягыннан камиллек»;

«Эчтәлек һәм интерактивлык»;

«Дизайн һәм юзабилити».

## VIII. Гариза кабул итү тәртибе

8.1. Гаризалар электрон рәвештә бәйгенең рәсми сайтында http://konkurs.belem.ru (алга таба – рәсми сайт) кабул ителә.

8.2. Гариза кабул ителгәндә, интернет-проектның статусы үзгәргәндә (расланганда / кире кагылганда) гариза тапшыручы күрсәткән электрон адреска хат җибәрелә.

8.3. Гаризалар түбәндәге очракта кабул ителми:

интернет-проект эчтәлеге тематикага, хокукый яисә әдәп нормаларына туры килми;

гариза бирү моментына сайт техник яктан әзер түгел (сайтның кайбер бүлекләрендә мәгълүмат юк яисә алар ачылмыйлар һ.б.);

гаризада күрсәтелгән мәгълүмат чынбарлык белән туры килми;

интернет-проект бер айдан бирле яңартылмаган;

гаризаларны кабул итү вакытында интернет-проект эшләми (хостинг эшләми, доменны куллану вакыты узган);

интернет-проектның файдалы оригиналь эчтәлеге юк;

интернет-проект Internet Explorer, Mozilla Firefox, Google Chrome яисә Opera браузерларының соңгы версияләрендә дөрес күрсәтелми;

интернет-проект әле эшләнә генә яисә кайбер бүлекләренә кергәндә 404 хатасын («бит табылмады») бирә;

интернет-проектның дизайны бөтенләй юк яисә шаблон нигезендә генә сыйфатсыз эшләнелгән;

интернет-проектта хокукый яисә әдәп нормаларына туры килми торган реклама урнаштырылган;

интернет-проектта татар телендә контент (интерфейс, эчтәлек, ресурслар) бик аз, тулаем контентның яртысыннан кимен тәшкил итә;

интернет-проект социаль челтәрнең бер сәхифәсе генә яисә чаттан гыйбарәт, теркәлгәннән соң гына яисә махсус программа нигезендә эшли торган ресурс буларак кына урнаштырылган.

8.4. Төзәтүләр керткәннән соң, Оештыру комитеты рөхсәте белән гаризаны яңадан тапшыру мөмкин.

## IX. Бәйгене үткәрү тәртибе

9.1. Бәйгене үткәрү этаплары Оештыру комитеты тарафыннан билгеләнә һәм бәйгенең рәсми сайтында урнаштырыла.

9.2. Бәйгенең номинацияләре:

«Укытучы – җәүһәр» номинациясе. Әлеге номинациядә укытучы шәхесенә һәм аның эшчәнлегенә багышланган, интернет-проектны ясауда укытучы(лар) үз(ләр)е төп өлеш керткән интернет-ресурслар катнаша ала;

«Укучы – җәүһәр» номинациясе. Әлеге номинациядә укучы(лар) ясаган һәм үзләренең белем алу белән бәйле эшчәнлекләрен чагылдырган интернет-ресурслар катнаша ала;

«Гаилә һәм башлангыч белем җәүһәрләре» номинациясе. Әлеге номинациядә балалар бакчасы/башлангыч мәктәп тормышын чагылдырган, башлангыч белем бирүгә багышланган яисә интернет-проектны ясауда шул яшьтәге баланың зур өлеше кергән, гаиләләр ясаган, гаиләләр өчен ясалган, иман һәм тәрбия өлкәсендә файдалы мәгълүмат чыганагы булган интернет-ресурслар катнаша ала;

«Урта белем - яшь җәүһәрләр» номинациясе. Әлеге номинациядә урта гомуми белем мәктәбе тормышын яисә урта белем бирү мәктәпләрендә эшләп килүче түгәрәкләр эшен чагылдырган интернет-ресурслар катнаша ала;

«Югары белем – фән җәүһәрләре» номинациясе. Әлеге номинациядә махсус урта һәм югары уку йортлары тормышын чагылдырган интернет-ресурслар, студентларның һәм фән хезмәткәрләренең фәнни темага багышланган интернет-проектлары, фән үзәкләре һәм китапханәләрнең сайтлары катнаша ала;

«Тематик ресурс - иҗади җәүһәр» номинациясе. Әлеге номинациядә татар мәдәниятенә, аның тарихына, шулай ук белем һәм тәрбия бирү өчен зур әһәмияткә ия булган, төрле файдалы темаларга багышланган интернет-ресурслар катнаша ала;

«.tatar домены - җәүһәрләр чыганагы» номинациясе. Әлеге номинациядә .tatar доменында урнашкан, татар телендә киң катлау укучылар өчен файдалы мәгълүмат чыганагы булган интернет-ресурслар катнаша ала;

«Күренекле татар җәүһәрләре» номинациясе. Әлеге номинациядә күренекле татар шәхесләренә (галимнәр, язучылар, шагыйрьләр, драматурглар, артистлар, рәссамнар, дәүләт эшлеклеләре, спорт осталары, табиблар һ.б.) багышлап ясалган бай мәгълүматлы интернет-проектлар катнаша ала.

9.3. «Белем җәүһәре» исеменә лаек булып өч елдан артык актив эшләп килгән интернет-проектлар бәйгенең махсус «Җәүһәрләрнең җәүһәре» исеменә (гран-при) лаек дип табылалар, махсус диплом һәм аеруча кыйммәтле истәлекле бүләк белән бүләкләнәләр.

9.4. Бәйге турында тулы мәгълүматны бәйгенең рәсми сайтында алырга мөмкин.

Документ создан в электронной форме. № исх-2185/16 от 24.08.2016. Исполнитель: Каримов Р.Т.
Страница 5 из 6. Страница создана: 24.08.2016 16:42
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Лист согласования к документу № исх-2185/16 от 24.08.2016
Инициатор согласования: Каримов Р.Т. Ведущий советник отдела национального образования
Согласование инициировано: 23.08.2016 16:48

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Шарипова А.С. | | Согласовано<br>24.08.2016 - 16:43 | - |
| 2 | Исмагилова Г.Х. | | Согласовано<br>24.08.2016 - 16:47 | - |
| 3 | Мухаметов И.Р. | | Подписано<br>24.08.2016 - 20:46 | - |



Документ создан в электронной форме. № исх-2185/16 от 24.08.2016. Исполнитель: Каримов Р.Т.
Страница 6 из 6. Страница создана: 25.08.2016 09:27